РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Учаллинского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Советская, д.51, Азнакаевский район,
с.Учалле, 423317
тел./факс (885592)36-8-32
E-mail: Uchal.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Үчәлле авыл җирлеге
башкарма комитеты

Совет ур., 51 нче йорт, Азнакай районы
Үчәлле авылы, 423317
тел./факс (885592)36-8-32
E-mail: Uchal.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«15»апрель 2022ел** **№ 10**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 гыйнварындагы 87 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү хакында (22.11.2016 елгы №46, 22.11.2016 елгы №47, 02.09.2017 елгы №66, 03.07.2018 елгы №104, 15.03.2019 елгы №136, 19.02.2020 елгы №169, 05.04.2021 елгы №36 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8,33 статьяларына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Үчәлле авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясенең 11.04.2022 елгы бәяләмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Үчәлле авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 гыйнварындагы 87 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү хакында (22.11.2016 елгы №46, 22.11.2016 елгы №47, 02.09.2017 елгы №66, 03.07.2018 елгы №104, 15.03.2019 елгы №136, 19.02.2020 елгы №169, 05.04.2021 елгы №36 карарлар редакциясендә)

1.1. 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 3 статьясы һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 57 статьясы белән туры китерергә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү эшләрен башкару тәртибен һәм срокларын билгеләргә (1 нче кушымта).

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Г.М.Төхвәтуллина

Азнакай муниципаль районы авыл җирлеге башкарма комитет карарына 1 нче кушымта
15.04.2022ел №10

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләүнең якынча сроклары**

| N | «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә керү турында проектны әзерләү эшләрен уздыру тәртибе | Эшләрне башкару вакыты |
|---|---|---|
| 1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект әзерләү эшләрен оештыру. | 2022 елның II кварталы |
| 2.<br><br>2.1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү һәм килештерү.<br>Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренең шәһәр төзелеше регламентларына үзгәрешләр кертү, җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын килештерүдә катнашучы хезмәтләрнең һәм ведомстволарның искәрмәләренә шәрехләр әзерләү. | 2022 елның II кварталы |
| 3.<br><br><br>3.1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект буенча фикер алышу.<br>Ачык тыңлаулар үткәрү.<br>Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге башлыгына "Үчәлле авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын һәм аңа карата мәҗбүри кушымталарны (ачык тыңлаулар беркетмәсе һәм ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә) Карар кабул итү өчен җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын авыл җирлеге Советына раслауга яисә кире кагуга һәм аны кабат эшләп бетерү датасын күрсәтеп, эшләп бетерергә җибәрү. | III квартал 2022 ел |